СОВЕТ ИШКЕЕВСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МАМАДЫШСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
ул.Школьная, д.18, с. Ишкеево, Мамадышский район, Республика Татарстан, 422161

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МАМАДЫШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ ИШКИ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Мәктәп ур., 18 нче йорт, Ишки авылы, Мамадыш районы, Татарстан Республикасы,422161

тел.(факс): (85563) 2-41-19; e-mail: Ishk..Mam@tatar.ru, www:mamadysh.tatarstan.ru

**Решение** **Карар**

от 18.09.2019 года № 1-45

Референдум уздыру инициативасы турында

«Россия Федерациясе гражданнары сайлау хокукларының һәм референдумда катнашу хокукының төп гарантияләре турында» 2002 ел, 12 июнь, 67-ФЗ номерлы Федераль законның 15 статьясы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 ел, 6 октябрь, 131-ФЗ номерлы Федераль законның 22, 56 статьялары, «Җирле референдум турында» 2004 ел, 23 март, 23-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 12 статьясы, «Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районының Ишки авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставының 11 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге Советы К А Р А Р К А Б У Л И Т Т Е:

1.Түбәндәге сораулар буенча җирле референдум үткәрү инициативасы белән чыгарга:

«Татарстан Республикасы Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән балигъ булган гражданнарга, 1 һәм 2 группа инвалидлар, Бөек Ватан сугышы һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашкан ветераннар, Бөек Ватан сугышында һәм хәрби хәрәкәтләрдә катнашканнарның тол хатыннары, күп балалы гаиләләр, көндезге бүлектә белем алучы студентлар, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән кала, 2020 елда 400 сум күләмендә үзара салым кертелүгә һәм ул акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү өчен тотылуына сез ризамы:

-Ишки авылында Яшьләр урамы, Васильево авылында К.Маркс урамы юлларын вак таш белән ремонтлау (сатып алу, вак таш җәю, килешү буенча эш өчен түләү)

-Ишки авылында Мәктәп урамына, Яшьләр урамына янгын гидрантлары җайланмаларын сатып алу һәм урнаштыру;

-Ишки һәм Васильево авылларындагы юлларны тигезләү һәм кардан чистарту.

« ӘЙЕ » « ЮК »

2. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында, Мамадыш муниципаль районы mamadysh.tatarstan.ru сайтында, Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (pravo.tatarstan.ru.) урнаштырырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен Мамадыш муниципаль районы Ишки авыл җирлеге башлыгы Р.К.Хафизовка йөкләргә.

Мамадыш муниципаль районы
Ишки авыл җирлеге башлыгы,
Совет председателе Р.К.Хафизов